| | |
|---|---|
| СОВЕТ КРЫМ-САРАЙСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЫРЫМ-САРАЙ АВЫЛ<br>ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.05.2024 Кырым-Сарай авыл №114

Баулы муниципаль районы
Кырым-Сарай авыл җирлеге
Советының 16.10.2019 №115
бюджет төзелеше һәм «Баулы
муниципаль районы "Кырым-Сарай
авыл җирлеге" муниципаль
берәмлегендә бюджет процессында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 19.12.2022 № 521-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Кырым-Сарай авыл җирлеге Советы Баулы шәһәр прокуратурасының 14.03.2024 №02-08-02/24 протесты нигезендә карар чыгарды:

1. Баулы муниципаль районы Кырым-Сарай авыл җирлеге Советының 16.10.2019 №115 карары белән расланган Баулы муниципаль районының «Кырым-Сарай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә кертергә (16.12.2019 №129, 13.03.2020 №132 кертелгән үзгәрешләр белән) 13.05.2020 №140, от 16.11.2021 №37, 16.06.2022 №55, 18.12.2023 №104) түбәндәге үзгәрешләр:

5 нче маддәдә:

66 нчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Бюджет йөкләмәләрен кабул итәләр һәм аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертәләр;»

72 нче абзацны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

- муниципаль контрактлар, Бюджет кодексы нигезләмәләрендә һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка федераль законнарда каралган очракта, бюджет йөкләмәләренең расланган лимитлары гамәлдә булу срогы чикләреннән тыш, мондый муниципаль контрактлар, башка килешүләр

буенча йөкләмәләрне үтәүне күздә тоткан башка килешүләр төзиләр. Муниципаль контрактлар, башка килешүләр төзү өчен билгеләнгән күрсәтелгән Нигезләмәләр элек төзелгән муниципаль контрактларга, башка килешүләргә үзгәрешләр керткәндә дә кулланыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык, Совет Рәисе
Кырым-Сарай авыл җирлеге башлыгы Д. А. Шакирҗанов